**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1555**
**30.03.2020**

Башкарма комитетның
аерым карарлары үз көчен
югалтуын тану турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитет Җитәкчесенең «Намуссыз төзүчеләрнең гамәлләреннән зыян күргән күпфатирлы йортларны өлешләп төзүдә катнашучылар реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2008 елның 8 апрелендәге 779 номерлы карары;

2) Башкарма комитет Җитәкчесенең «Башкарма комитет Җитәкчесенең «Намуссыз төзүчеләрнең гамәлләреннән зыян күргән күпфатирлы йортларны өлешләп төзүдә катнашучылар реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2008 елның 8 апрелендәге 779 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 20 июнендәге 1870 номерлы карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов